КАРАР
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Югары Стәрле авыл җирлеге Советы

Югары Стәрле авылы № 10-3 2 октябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендә 116 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында (14.08.2015 №141, 10.10.2018 №112-72, 24.06.2019 №139-86, 05.11.2019 №150-91карарлар редакциясендә)

2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, Югары Стәрле авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендә 116 номерлы "Җир салымы турында" карарына (14.08.2015 №141, 10.10.2018 №112-72, 24.06.2019 №139-86, 05.11.2019 №150-91карарлар редакциясендә), 7 нче пунктны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басма - "Маяк" газетасында басылганнан соң бер ай үзгач, үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С.Сабирҗанова